ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НУРЛАТСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК РАЙОНЫ
НОРЛАТ
АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
«05» декабрь 2024 ел

КАРАР
№ 25

Зеленодольск муниципаль районы Норлат авыл җирлеге башкарма комитеты баш бухгалтерының һәм бухгалтерларының хезмәтенә түләүне оештыру һәм шартлары турындагы нигезләмәне (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш)раслау хакында.

Бухгалтерлык хезмәте хезмәткәрләренең хезмәтенә түләүне камилләштерү максатларында Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Норлат авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

5. Зеленодольск муниципаль районы Норлат авыл җирлеге башкарма комитеты баш бухгалтеры һәм бухгалтерларының хезмәтенә түләүне оештыру һәм шартлары турындагы нигезләмәне (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) расларга.
6. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.
7. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый информация рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре составындагы Зеленодольск муниципаль районы информация сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук Норлат авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында: Норлат авылы, Гагарин урамы, 46 йорт (җирлек администрациясе бинасы), Норлат авылы, М. Фәйзуллин урамы, 17 йорт («Идел Арьягы»үзәге бинасы) урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

И.М.Саттаров

Норлат авыл җирлеге башкарма комитеты 5 нче декабрь 2024 ел 25 нче карарына 1 нче кушымта

Зеленодольск муниципаль районы Норлат авыл җирлеге башкарма комитеты баш бухгалтеры һәм бухгалтерларының хезмәтенә түләүне оештыру һәм шартлары турында нигезләмә (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш).

1. Зеленодольск муниципаль районы Норлат авыл җирлеге башкарма комитеты баш бухгалтеры һәм бухгалтерларының хезмәтенә түләүне оештыру һәм шартлары турында әлеге Нигезләмә (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) (алга таба - нигезләмә) эшчәнлекне оештыруның аерым мәсьәләләрен регламентлый һәм хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәрен, компенсация һәм кызыксындыру характерындагы түләүләр күләмнәрен һәм аларны бирү шартларын билгели.

2. Бухгалтерларның хезмәт хакы вазыйфаи окладтан, тиешле еллар эшләгән өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмәдән, эш интенсивлыгы өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмәдән, акчалата бүләкләүдән, матди ярдәмнән һәм еллык түләүле отпуск биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләүдән, эш нәтиҗәләре буенча премияләрдән гыйбарәт.

3. Бухгалтерларның вазыйфаи окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

- Баш хисапчы - 25700 сум;
- Бухгалтер - 24500 сум".

«Норлат авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының штат расписаниесенә бухгалтер вазыйфасын кертү шарты булып муниципаль берәмлектә 1,9 меңнән артык кеше яшәве тора.

4. Бухгалтерларга билгеләнә:

1) тиешле еллар эшләгән өчен вазыйфаи окладка ай саен түбәндәге күләмнәрдә өстәмә:

| Эш стажы булганда | Айлык өстәмә, процентлар |
|---|---|
| 1 елдан 5 елга кадәр | 5 |
| 5 елдан 10 елга кадәр | 7 |
| 10 елдан 15 елга кадәр | 10 |
| 15 елдан артык | 15 |

2) эш интенсивлыгы өчен вазыйфаи окладка ай саен вазыйфаи окладның 10 проценты күләмендә өстәмә түләү;

3) еллык түләүле отпуск биргәндә бер елга вазыйфаи окладның 120 проценты күләмендә бер мәртәбә түләү;

Әгәр бухгалтерларга календарь ел дәвамында еллык түләүле отпуск бирелмәсә, бер тапкыр бирелә торган түләү аңа декабрьдә эштән киткән вакытка пропорциональ рәвештә исәпләнә һәм түләнә, эштән киткән очракта - соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча.

Эшнең беренче елында еллык түләүле отпуск бирелгәндә бухгалтерларга бер

мәртәбә түләү календарь елында эшләнгән вакытка пропорциональ рәвештә башкарыла. Эшләнгән вакыт агымдагы календарь елның 31 декабренә кадәр эшкә кергән көннән исәпләнә.

4) билгеләнгән хезмәт өчен түләү фонды чикләрендә акчалата бүләкләү, матди ярдәм;

5) эш нәтиҗәләре буенча премияләр (премияне түләү шартлары, ешлыгы, күләмнәре хезмәт өчен түләүнең гамәлдәге шартларыннан чыгып билгеләнә).

5. Бухгалтерларның еллык хезмәт хакы фонды түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$FOT = \sum_{1}^{n}((O_d + 0{,}3 * O_d) * k) * (1 + t)$$

кайда:

$FOT$ – бухгалтерларның еллык хезмәт хакы фонды;

$O_d$ - бухгалтерга айга вазыйфаи окладлар түләүгә акчалар суммасы;

$0{,}3 * O_d$– тиешле еллар эшләгән өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә түләүгә, эш интенсивлыгы өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә түләүгә, акчалата бүләкләүгә, еллык түләүле отпуск, матди ярдәм күрсәткәндә бер мәртәбә түләүгә акчалар суммасы;

$n$ – бухгалтерларның штат саны;

$k$ – 12 ай;

$t$ – хезмәткә түләү буенча түләүләргә исәпләүләр.